**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге Елаур торак пункты гражданнар җыены КАРАРЫ**

**17 октябрь 2023 ел** **№ 10**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге Елаур торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Елаур торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге поселок эчендәге юлларны ремонтлау (юл япмасын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш салу, транспорт хезмәтләре), шул исәптән поселок эчендәге юлларны сезонлы карап тоту;

Роторлы чапкыч сатып алу;

балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В. Охотникова